Совет Старочукалинского
сельского поселения Дрож-
жановского муниципального
района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Иске Чокалы
авыл җирлеге Советы

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12
ОГРН 1061672003876 ИНН 1617003290

==========================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы

19 октябрь 2022 ел № 20/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләүләре күләмнәрен һәм айлык вазыйфа окладларын индексацияләү турында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен, Рәис урынбасарларын, аудиторларын һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында»2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль район Советының 08.09.2022 ел, №21/9 карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының 24.04.2018 ел, № 29/1 (23.05.2018 ел, № 30/1, 11.09.2018 ел, № 34/2, 14.11.2018 №40/2, 14.01.2019 ел, №43/2, 13.11.2020 ел, № 3/4редакциясендә) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлек башлыкларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының акчалата

бүләкләүләре һәм айлык вазыйфа окладлары күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга (индексацияләргә) ,

2.Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең акчалата бүләкләре һәм вазыйфа окладлары күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәмә өстәмәләр һәм (индексацияне арттырганда) түләүләр бер сумга кадәр арта;

әлеге карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге бюджетында тиешле финанс елына каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

Иске Чокалы авыл җирлеге
Башлыгы: Р.Р.Низамутдинов